# КАРАР

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«24» ноябрь 2019 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2019 елның 10 ноябрендә, 17 нояредә, 24 ноябрендә узган: «Сез, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән I төркем инвалидларыннан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның толларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны:

1)Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм грунт-вак таш сибү;
2) Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару;

3) Муса Җәлил һәм Үзәк урамнарына янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыруга юнәлтү белән килешәсезме?” мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 601 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 389 кеше катнашты.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 386кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 3катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1 Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.
2. «Сез, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән I төркем инвалидларыннан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның толларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны:

1)Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм грунт-вак таш сибү;
2) Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару;

3) Муса Җәлил һәм Үзәк урамнарына янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыруга юнәлтү белән килешәсезме?» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чулпан авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыены рәисе: Ф.Ф.Зыятдинов

Чулпан авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Зыятдинов